| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2018 елның 31 августы Баулы шәһәре № 83

Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районы «Баулы шәһәре»
муниципаль берәмлеге Башкарма
комитеты җитәкчесе вазифасын
биләүгә конкурс игълан итү турында

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатуы белән бәйле рәвештә, 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131нче номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль Законның 37нче статьясына, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июнендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Законының 26нчы статьясына, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт Кодексының 20нче статьясына, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 50нче статьясына таянып, Баулы шәһәре Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс игълан итәргә.

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә дәгъва кылучылардан документларны 2018 елның 5 сентябреннән 2018 елның 26 сентябренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул итәргә:

Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20нче йорт, 310нчы кабинет, эш көннәрендә 8дән 17 сәгатькә кадәр, тел. (85569) 6 07 12.

2. Конкурс комиссиясе Конкурсны 2018 елның 27 сентябрендә Баулы муниципаль районы Советы бинасында (Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20нче йорт) сәгать 10да Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә ярашлы рәвештә әлеге карарга 1нче кушымта нигезендә үткәрергә һәм конкурс нәтиҗәләре, кандидатлар турында мәгълүматны Баулы шәһәре Советына бирергә тиеш.

3. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә дәгъва кылучылар кандидатураларын тикшерүче конкурс комиссиясенең составын 6 кешелек итеп билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә дәгъва кылучылар кандидатураларын тикшерүче конкурс комиссиясенең яртысын 2нче кушымтага нигезләнеп билгеләргә.

5. Әлеге Карарны «Хезмәткә дан» («Слава труду») газетасында 2018 елның 5 сентябрендә бастырырга һәм Баулы муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы рәисе

АППАРАТ СОВЕТА
СОВЕТ АППАРАТЫ

Р.Х. Гатиятуллин

Баулы шәһәр Советының 2018 елның 31
августындагы 83нче карарына 1нче
кушымта

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә, 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131нче номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидәрә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль Законның 37нче статьясына, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июнендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Законының 26нчы статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе (алда – Башкарма комитет җитәкчесе) вазифасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурсның (алда – конкурсның) төп максаты булып Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алда – Башкарма комитет) эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру, кадрларны һөнәри осталык, эшлеклелек һәм әхлакый сыйфатлар буенча сайлау һәм билгеләүне камилләштерү, кадрларга идарә итү һәм методика эшен камилләштерүгә стимул бирү тора.

3. Конкурс үткәрү өчен Баулы шәһәр Советы (алда – Совет) конкурс комиссиясе булдыра. Конкурс комиссиясе составы, аның эше сроклары һәм тәртибе әлеге Нигезләмә белән билгеләнә.

4. Конкурс комиссиясе 6 кешедән тора.

5. Конкурс комиссиясенең ярты составы Совет тарафыннан, икенче яртысы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.

6. Конкурс комиссиясе рәисе, аның урынбасары, секретаре Совет тарафыннан билгеләнә.

7. Конкурс Совет карары белән игълан ителә.

8. Конкурс түбәндәге шартларда үткәрелә:

1) Башкарма комитет җитәкчесе вазифасына кандидат түбәндәгеләргә ия булырга тиеш:

а) Россия Федерациясе гражданлыгы;

б) «дәүләт һәм муниципаль идарә» белгечлеге буенча югары һөнәри белем яки югары һөнәри белем;

в) муниципаль хезмәтнең баш яки әйдәп баручы муниципаль вазифаларында муниципаль хезмәт стажы яки аларга тәңгәл булган дәүләт хәзмәте вазифаларында хезмәт яки белгечлек буенча биш елдан да ким булмаган стаж;

г) биш елдан да ким булмаган идарә итү тәҗрибәсе. Идарә итү дигәнне милекчелек формасына бәйсез рәвештә оешма, дәүләт органы, җирле үзидарә органы җитәкчесе, җитәкче урынбасары вазифасында, шулай ук аларның структур подразделениеләре җитәкчеләре вазифасында эшләү дип аңларга кирәк;

д) Башкарма комитет җитәкчесе эш бурычларын башкару өчен зарур булган эшлекле сыйфатлар һәм күнекмәләр:

- һөнәри белемнәр, шул исәптән аның компетенциясенә керүче һәм Башкарма комитетка караган сорауларны хәл итүне билгеләүче Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, Федераль закончалыкны һәм Татарстан Республикасы закончалыгын, Баулы муниципаль районы “Баулы шәһәре” Уставын һәм башка хокукый актларны белү;

- Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге социаль-икътисади үсеше стратегиясен һәм аңа йөкләнгән вазифаларны үтәү буенча Башкарма комитетның эчшәнлеген билгели алу, андый эшчәнлекнең яңа

формаларын һәм ысулларын эзләү, аларны тормышка ашыруның механизмнарын булдыру;

- үз эшчәнлеген, Башкарма комитет эшчәнлеген, аның органнары һәм Башкарма комитет җитәкчесенә буйсынган хезмәткәрләренең эшен планлаштыра, оештыра һәм анализлый алу;

- этик нормаларны белү һәм аларны аралашуда куллана алу;

2) Кандидатның муниципаль хезмәткә урнашканда һәм аны башкарганда муниципаль хезмәт турындагы закончалыкта каралган чикләүләре булмау.

9. Башкарама комитет җитәкчесе вазифасына конкурс үткәрү һәм конкурста катнашуга документлар кабул ителү турында белдерү «Хезмәткә дан» («Слава труду») газетасында һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында басыла.

10. Конкурс үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелә:

1) вазифаның тулы атамасы;

2) әлеге вазифаны биләүгә дәгъва кылучыга булган таләпләрне үз эченә алган конкурс шартлары;

3) конкурс үткәрү көне, вакыты, урыны;

4) әлеге Нигезләмәнең 12нче пункты нигезендә бирелергә тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, ул документларны кабул итү срогы;

5) Башкарма комитет җитәкчесе белән төзелә торган контракт проекты;

6) конкурс турында тәфсилле мәгълүматны каян алып булуы турында мәгълүмат (телефон, факс, электрон почта, электрон адрес).

11. Конкурс турында белдерү конкурс үткәрүгә кимендә 20 көн кала бастырыла.

12. Конкурста катнашырга теләүче затлар конкурс комиссиясенә гариза һәм түбәндәге документларны тапшыралар:

1) үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, 4 х 6лы зурлыктагы фотография һәм автобиография;

2) паспортның яки аны алыштыручы документның төп нөсхәсе һәм күчермәсе (тиешле документ документлар тапшырганда һәм конкурска килгәндә шәхсән күрсәтелә);

3) югары белемне, хезмәт стажын һәм квалификацияне раслаучы документлар:

- хезмәт кенәгәсе яки гражданинның хезмәт эшчәнлеген раслаучы башка документның төп нөсхәсе һәм күчермәсе;

- һөнәри белем турында документларның төп нөсхәсе һәм күчермәсе, шулай ук, гражданинның ихтыяры нигезендә, нотариус яки хезмәт урынында кадрлар хезмәте раслаган өстәмә һөнәри белем, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем турындагы документлар;

4) Муниципаль хезмәткә урнашкан ел алдындагы елдагы керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр;

5) муниципаль хезмәткә урнашуга комачауларлык авыруы булмавы турында медицина учреждениесе бәяләмәсен;

Кандидат конкурста һөнәри әзерлеген сыйфатларлык башка документларны күрсәтә ала.

13. Гариза һәм аңа беркетелгән документлар махсус журналда теркәлә, аларга регистрация тәртип номеры куела.

Гариза тапшырган затка, исемлеген һәм вакытын күрсәтеп, документлар кабул ителүе турында расписка бирелә.

14. Тапшырылган документларны конкурс комиссиясе секретаре кабул итә һәм тикшерә. Документларның төп нөсхәләре гариза бирүчегә шул ук көнне кайтарыла, ә документларның күчермәләре эш буларак туплана.

15. Әлеге Нигезләмәнең 12нче пунктында күрсәтелгән документлар конкурс комиссиясенә конкурс үткәрелү турында белдерү басылганнан соң 20 көн эчендә тапшырыла.

Документларны вакытында тапшырмау, аларны тиешле күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

16. Конкурс гаризалар кабул итү вакыты тәмамлангач 30 көн эчендә үткәрелә.

17. Конкурс Башкарма комитет җитәкчесе вазифасына кандидатларның һөнәри әзерлек дәрәҗәсен, әлеге вазифаның квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

18. Тапшырылган документлар нигезендә конкурс комиссиясе кандидатларны конкурста катнаштыру яки катнаштырмау турында карар кабул итә.

19. Башкарма комитет җитәкчесе квалификация таләпләренә туры килмәсә, шулай ук муниципаль хезмәткә урнашканда һәм аны башкарганда муниципаль хезмәт турындагы закончалыкта каралган чикләүләре булса гражданинга конкурста катнашуга рөхсәт бирелми.

Конкурста катнашуга рөхсәт бирелмәсә, гражданин бу карарга карата судка шикаять бирә ала.

20. Конкурс барышында конкурс комиссиясе кандидатларга бәяне алар тапшырган белем, гражданлык яки дәүләт һәм муниципаль хезмәт, башка хезмәт эшчәнлеге турындагы документлар, шулай ук Россия Федерациясе норматив-хокукый актларына каршы килмәгән башка бәяләү ысуллары нигезендә бирә, шул исәптән кандидатларның үз программаларын тапшыуларын, шәхси сөйләшүне дә кертеп.

21. Кандидатларны конкурска сайлап алу конкурс комиссиясе утырышларында үткәрелә.

Конкурс комиссиясе утырышында әлеге Нигезләмәнең 4нче пунктында күрсәтелгән конкурс комиссиясе әгъзалары санының өчтән икесеннән дә ким булмаган өлеше катнашса, утырыш үткән булып исәпләнелә. Конкурс комиссиясе карарларны гади күпчелек тавыш белән кабул итә.

22. Конкурс комиссиясе карарлары кандидат югында кабул ителә.

23. Конкурс комиссиясе тавыш бирүе нәтиҗәләре конкурс комиссиясе рәисе, секретаре һәм утырышта катнашкан әгъзалары имзасы куелган карар белән рәсмиләштерелә.

24. Конкурс нәтиҗәләре һәм кандидатлар турында мәгълүматны конкурс комиссиясе рәисе конкурс тәмамлангач өч көн эчендә Советка җиткерә.

25. Конкурс комиссиясе конкурс сайлап алуы нәтиҗәсе буенча Советка Башкарма комитет җитәкчесе вазифасына дәгъва кылучы кимендә ике кандидатны күрсәтә.

26. Конкурс нәтиҗәсендә Башкарма комитет җитәкчесе вазифасы квалификация таләпләренә туры килә торган кандидатлар ачыкланмаса, Совет конкурсны кабат үткәрү турында карар кабул итә.

Конкурс комиссиясе күрсәткән кандидатларның берсе дә Башкарма комитет җитәкчесе вазифасына билгеләү өчен кирәк булган Совет депутатлары тавышларын җыя алмаган очракта да Совет конкурсны кабат үткәрү турында карар кабул итә.

27. Конкурс комиссиясе конкурста катнашкан кандидатларга конкурс нәтиҗәләрен ул тәмамлангач өч көн эчендә язмача хәбәр итә.

28. Башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүгә дәгъва кылган, әмма конкурста катнашу рөхсәте алмаган претендентларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары аларга конкурс тәмамланганнан соң өч ел эчендә язмача гариза нигезендә кайтарыла ала. Әлеге срок тәмамланганчы алар Советта саклана, аннары юк ителергә тиеш.

29. Конкурста катнашу белән бәйле чыгымнарын (конкурс урынына бару-кайту, торак алып тору, элемтә чаралары белән файдалану һәм башкалар) кандидатлар үзләре күтәрәләр.

Баулы шәһәре Советының
2018 елның 31 августында
кабул ителгән 83нче санлы
карарына 2нче кушымта

Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә дәгъва кылучылар кандидатураларын тикшерүче конкурс комиссиясе составының яртысы

| | |
|---|---|
| Корбанов Кәрим Фатхетдин улы | Баулы шәһәре Советы депутаты, комиссия рәисе |
| Халитова Айгөл Риф кызы | Баулы муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары |
| Хәйруллина Алия Илдар кызы | Баулы муниципаль районы Советы Аппараты кадрлар белән тәэмин итү бүлеге начальнигы, комиссия секретаре |